| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРАХЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАКЧЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| 422661, с. Урахча, ул. Совет, дом 36А | 422661, Уракчы авылы, Совет урамы, 36А нче йорт, |

Тел.: (84361) 29435, факс: (84361) 29435, e-mail: Urah.Rs@tatar.ru,
сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 7 декабре Уракчы ав. № 16

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл жирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге "Адрес бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 12 номерлы карары белән расланган административ регламентка үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елнын 30 июлендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 12 номерлы карары белән расланган "Адрес бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Регламенттагы дәүләт адреслар реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслар системасын эксплуатацияләүгә бәйле булган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына,"Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2013 елнын 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законга,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында" 2014 елнын 19 декабрендәге 1221 номерлы карарына төгәл туры китереп кулланыла.";

1.2. 1.5 пунктының 11 - 17 абзацларын тиндәшле рәвештә 3 - 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4 - 7 пунктчаларында “Башкарма комитет” сүзен “төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет” сүзләренә алмаштырырга;

1.4.2.6.1 пунктының 8 пунктчасында “Башкарма комитет” сүзен “төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет” сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4.пунктында“Башкарма комитетның структур бүлекчәсе” сүзләрен “муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет”сүзләренә алмаштырырга;

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Уракчы авылы, Совет ур., 36А йорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров ур., 20 Б адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнән җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы Ф.М. Гәрәев